| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.07.2026 с.Старое Дрожжаное № 27

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисенең 2026 елның 9 апрелендәге 279 нчы номерлы «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Президентының Указына үзгәрешләр кертү хакында»гы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге эшчәнлекне оештыруны камилләштерү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 13 ноябрендәге 50 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе турында»гы карарына (25.02.2020 № 11 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 3, 4 пунктларны** төшереп калдырырга;

2) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе турында нигезләмә» **1 нче кушымтада:**

**а) 2 нче пунктта** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

**б) 4 нче пунктны** төшереп калдырырга**;**

**в) 6 нчы пунктта:**

**а пунктчасында** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле **и) пунктчасын** өстәргә:

«и) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләргә, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларга карата чыгымнарны контрольдә тоту барышында алынган нәтиҗәләрне карый;»;

**3)** «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын хәл итү белән бәйле мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмә» **3 нче номерлы кушымтаны** төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына тиешле авыл җирлегендә гамәлдә булган коррупциягә каршы көрәш комиссиясе (советы) турындагы нигезләмәгә кирәкле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында тиешле авыл җирлекләре территориясендә коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе карарларын үтәү өчен кирәкле чаралар күрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башлык: М.Р. Гафаров